ГОСУДАРСТВЕННАЯ
ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Б.Красная, д.15/9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ
ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ
З.Кызыл ур., 15/9 й., Казан шәһәре, 420111

тел/факс. 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ 200

**П Р И К А З** **Б О Е Р Ы К**

« 17 » 12 20 14 ел.

**Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеге башкару өчен лицензия бирүгә карата дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында**

2011 елның 04 маендагы “Аерым эшчәнлек төрләрен лицензияләү турында” №99-ФЗ Федераль закон, 2014 елның 28 октябрендәге “Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген лицензияләү турында” №1110 Россия Федерациясе Хөкүмәте Карары һәм Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2014 елның 24 октябрендәге “Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген лицензияләүгә карата дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ регламент, лицензия контроле буенча дәүләт функциясе үтәлүнең административ регламентын, күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген лицензияләгәндә кулланыла торган документларның рәвешләрен эшләү буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында” №657/пр боерыгы нигезендә

**б о е р ы к б и р ә м:**

1. Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеге башкару өчен лицензия бирүгә карата дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын расларга (алга таба – Административ регламент).

2. Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеге башкару өчен лицензия бирүгә карата дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең вазифаи затларына расланган Административ регламентка таянып эш итәргә.

3. Административ тәҗрибә бүлеге башлыгына (Мөхәммәтшин Ф.Р.) әлеге боерык белән, шәхси имзалатып, Татарстан Республикасы Дәүләт торак

инспекциясе башлыгын, зоналардагы торак инспекциясе башлыкларын, бүлекләрдәге башлыкларны һәм ТР ДТИнең дәүләт хезмәте күрсәтүче вазифаи затларын таныштырырга.

4. Юридик бүлек башлыгына (Гафиятуллин А.Н.) әлеге боерыкны Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгына теркәүгә алу өчен җибәрергә.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башлык С.А. Крайнов

Татарстан Республикасы
Дәүләт торак инспекциясенең
2014 елның “17” ____12____
№ 200 боерыгы белән
РАСЛАНДЫ

**Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеге башкару өчен лицензия бирүгә карата дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеге башкару өчен лицензия бирүгә карата дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Административ регламент) күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеге башкару өчен лицензия бирүгә карата дәүләт хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте) күрсәтүнең тәртибен һәм стандартын билгели.

1.2. Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеге башкарырга нияте булган яки бу эшчәнлекне башкаручы юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр (алга таба тиешенчә – лицензия алырга теләүче, лицензиат); физик затлар һәм юридик затлар, лицензияләр реестрыннан өземтә рәвешендә күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеге башкару өчен аерым бер лицензия турында белешмәләр һәм (яки) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча башка төрле мәгълүмат алырга нияте булган физик затлар һәм юридик затлар дәүләт хезмәте алучы булып санала.

Хезмәт алучылар яисә алучы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә гамәл кылу вәкаләте бирелгән затлар дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать итүчеләр (алга таба – мөрәҗәгать итүчеләр) була.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе (алга таба – ТР ДТИ) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. ТР ДТИ урнашу урыны: Казан ш., З.Кызыл ур., 15/9 й.

ТР ДТИ эш графигы: шимбә һәм якшәмбедән кала көн саен, дүшәмбе – пәнҗешәмбе: 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр, җомга: 9.00 сәгатьтән 16.45 сәгатькә кадәр, төшке аш: 12.00-12.45 сәгатьләрдә.

Җәмәгать транспортында “Ирек мәйданы” тукталышына кадәр килергә:

– автобуслар: № 22, 28, 28а, 52, 89;

– троллейбуслар: № 7, 20, 21;

– метро (иң якын станция: “Кремль”).

Кертү кәгазе һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ ярдәмендә керергә була.

1.3.2. Лицензияләүне башкаручы бүлекнең (алга таба – бүлек) белешмә телефоннары: (843) 236-94-45

1.3.3. “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – “Интернет” челтәре) ТР ДТИ рәсми сайты адресы: https://gji.tatar.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) ТР ДТИ бинасында урнашкан, дәүләт хезмәте турында мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмати стендлар ярдәмендә;

2) “Интернет” челтәре аша:

ТР ДТИ рәсми сайтында (https://gji.tatar.ru.);

Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) ТР ДТИ телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яисә телефон аша);

4) ТР ДТИ язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә башкарыла:

Россия Федерациясенең Торак кодексы (алга таба – РФ Торак кодексы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2005, № 1, 14 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясенең Салым кодексы (икенче өлеше) (алга таба – РФ Салым кодексы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2000, № 32, 3340 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Россия Федерациясе Торак кодексына, Россия Федерациясенең аерым закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон чыгару актлары нигезләмәләрен гамәлдән чыккан дип тану турында” 21.07.2014 ел, №255-ФЗ Федераль закон (алга таба – №255 Федераль закон)

(Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2014, № 30 (1 ө.), 4256 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2011 елның 4 маендагы "Аерым эшчәнлек төрләрен лицензияләү турында" №99-ФЗ Федераль закон (алга таба – №99-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 19, 2716 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2008 елның 26 декабрендәге "Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында" №294-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2008, №52 (1 ө.), 6249 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2010 елның 27 июлендәге "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" №210-ФЗ Федераль закон (алга таба – №210 Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, №31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2009 елның 9 февралендәге "Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү турында" №8-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2009, № 7, 776 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2012 елның 7 маендагы "Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында" №601 Россия Федерациясе Президенты Указы (алга таба – №601 РФ Президенты Указы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 19, 2338 ст.);

2004 елның 26 февралендәге "Юридик затларны һәм шәхси эшмәкәрләрне дәүләт теркәвенә алу һәм исәпкә кую процедураларын камилләштерү турында" №110 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2004, № 10, 864 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2011 елның 21 ноябрендәге "Аерым эшчәнлек төрләрен лицензияләүне оештыру турында" №957 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 48, 6931 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2011 елның 6 октябрендәге "Лицензиянең үрнәк рәвешен раслау турында" №826 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (алга таба – 2011 елның 6 октябрендәге №826 РФ Хөкүмәте карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 42, 5924 ст.);

2009 елның 24 ноябрендәге “Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм федераль башкарма хакимият органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында” №953 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2009, № 48, 5832 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2012 елның 16 августындагы “Федераль башкарма хакимият органнары һәм аларның вазифаи затлары, федераль дәүләт хезмәткәрләре, Россия Федерациясенең дәүләт бюджеттан тыш фондларның вазифаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр тапшыру һәм карап тикшерү тәртибе турында” №840 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 35, 4829 ст.);

2014 елның 28 октябрендәге “Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген лицензияләү турында” №1110 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2014, № 44, 6074 ст.);

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2014 елның 28 октябрендәге “Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген лицензияләү өчен дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ регламент, лицензия контроле буенча дәүләт функциясе үтәлүнең административ регламентын, күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген лицензияләгәндә кулланыла торган документларның рәвешләрен эшләү буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында” №657/пр боерыгы (алга таба – Россия Төзелеш министрлыгының 2014 елның 28 октябрендәге №657/пр боерыгы);

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен рәсмиләштерү турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында” 02.11.2010 ел, №880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – №880 ТР МК карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмернамәләре, республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы, 08.12.2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 26.12.2011 ел, №1068 карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) (Татарстан Республикасы Министрлар

Кабинеты карарлары һәм әмернамәләре, республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы, 07.02.2012, № 10, 0383 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

1.5. Әлеге Административ регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гарызнамә аңлашыла (№210-ФЗ Федераль законның 2 ст., 1 п.). Гаризаларның рәвешләре Административ регламентка карата кушымталарда күрсәтелә.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Стандарт таләбенең исеме | Стандарт таләбенең эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең исеме | Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеге башкару өчен лицензия бирү | № 99-ФЗ Федераль закон,<br>РФ Торак кодексы. |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче органның исеме | Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе (алга таба – ТР ДТИ) | Нигезләмәнең 1.1 п. |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәләрен тасвирлау | а) лицензия бирү (бирүдән баш тарту);<br>б) лицензиядәге техник хатаны төзәтү;<br>в) лицензияне яңадан рәсмиләштерү (яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту);<br>г) лицензия алырга теләүче, лицензиат турындагы мәгълүматларны лицензияләр реестрына кертү;<br>д) лицензия дубликаты бирү;<br>е) лицензияләр реестрыннан өземтә рәвешендә аерым бер лицензия турында мәгълүматлар, ТР ДТИнең кабул ителгән карары турында акт күчермәсе яисә соралучы мәгълүматларның булмавы турында белешмә бирү;<br>ж) лицензиянең гамәлен туктату һәм лицензияне гамәлдән чыгару турында карар. | № 99-ФЗ Федераль законның 14, 17, 18, 20, 21 ст.;<br>РФ Торак кодексының 194, 199, 200 ст. |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты | а) ТР ДТИ тарафыннан мөрәҗәгать итүченең гаризасын һәм аңа теркәлүче документларны карап тикшерү – тиешле тәртиптә рәсмиләштерелгән лицензия бирү турында Административ регламентның 2.5 пунктында каралган гаризаны һәм аңа теркәлә торган тулы күләмдәге документларны (белешмәләрне) кабул | РФ Торак кодексының 194 ст. |

| | | |
|---|---|---|
| | иткән көннән соң 30 (утыз) эш көне дәвамында;<br>б) лицензия бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул итү – ТР ДТИ тарафыннан лицензия бирү яки аны бирүдән баш тарту турында нигезле тәкъдим Татарстан Республикасының лицензия комиссиясенә ирешкән көннән алып 10 (ун) эш көне дәвамында;<br>в) лицензияне яңадан рәсмиләштерү (яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту) турында карар кабул итү (юридик затны үзгәртеп төзү рәвешендә үзгәртеп корганда, аның исеме, урнашкан урынының адресы үзгәргәндә, шулай ук шәхси эшмәкәрнең яшәү урыны, исеме, фамилиясе һәм атасының исеме (булган очракта), аның шәхесен таныклый торган документ реквизитлары үзгәргәндә) – лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында Административ регламентның 2.5 пунктында каралган гариза һәм аңа теркәлә торган, документлар (белешмәләр) тулы күләмдә ТР ДТИ тапшырылган көннән алып 10 (ун) эш көне дәвамында;<br>г) лицензияне җибәрү – лицензияне имзалагач һәм лицензияләр реестрында теркәгәч 3 эш көне дәвамында;<br>д) лицензия дубликаты бирү – Административ регламентның 2.5 пунктында каралган гариза һәм документлар ТР ДТИ җиткерелгәннән соң 3 (өч) эш көне дәвамында;<br>е) лицензияләр реестрыннан өземтә рәвешендә аерым бер лицензия турында мәгълүматлар, ТР ДТИ кабул иткән карарлар турында акт күчермәсе яисә соралучы мәгълүматларның булмавы турында белешмәне бирү – документ (гариза) ТР ДТИ ирешкәннән соң 5 (биш) эш көне дәвамында;<br>ж) лицензиянең гамәлен туктату һәм лицензияне | № 99-ФЗ Федераль законның 14 ст. 14;<br>РФ Торак кодексының 201 ст.;<br>№1110 карарның 10 п.<br><br>№ 99-ФЗ Федераль законның 18 ст.<br><br>№ 99-ФЗ Федераль законның 14 ст.<br>№ 99-ФЗ Федераль законның 14 ст.<br><br>№ 99-ФЗ Федераль законның 21 ст.<br><br>№ 99-ФЗ Федераль законның 20 |

| | | |
|---|---|---|
| | гамәлдән чыгару – лицензияне гамәлдән чыгару турында үз көченә кергән суд карары (үз көченә кергән суд карарыннан өземтә) ТР ДТИ ирешкәннән соң 10 (ун) эш көне дәвамында. | ст. |
| 2.5. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле, закон чыгару яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган документларның тулы исемлеге | 1. Лицензия алу өчен түбәндәге документлар (белешмәләр) тапшырыла:<br>а) №99-ФЗ Федераль законның 13 ст. 1 ө. каралган мәгълүматларны күрсәтеп, лицензия бирү турында гариза;<br>б) лицензия алырга теләүченең вазифаи затының квалификация аттестаты күчермәсе;<br>в) теркәлә торган документларның исемлеге.<br>2. Лицензиядәге техник хатаны төзәтү өчен түбәндәге документлар (белешмәләр) тапшырыла:<br>а) техник хатаны төзәтү турында гариза;<br>б) техник хата киткән лицензиянең төп нөсхәсе;<br>в) техник хата булуны таныклаучы һәм юридик көчкә ия булган документлар.<br>3. Юридик затны үзгәртеп төзү рәвешендә үзгәртеп корганда лицензияне яңадан рәсмиләштерү өчен түбәндәге документлар (белешмәләр) тапшырыла:<br>а) лицензияне яңадан рәсмиләштерү өчен дәүләт пошлинасы түләгәнлекне раслый торган документларның реквизитларын, лицензиат яки аның хокукый варисы турында №99-ФЗ Федераль законның 13 статьясының 1 өлешендә каралган яңа мәгълүматларны һәм Бердәм дәүләт юридик затлар реестрына тиешле үзгәрешләр кертелүне раслый торган документ мәгълүматларын күрсәтеп, лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында гариза;<br>б) лицензиянең гамәлдәге чын нөсхәсе. | № 99-ФЗ Федераль законның 13, 14, 17, 18, 20, 21 ст.;<br>№1110 карарның 5, 6 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | 4. Юридик затны үзгәртеп төзү рәвешендә үзгәртеп корганда, аның исеме, урнашкан урынының адресы үзгәргәндә, шулай ук шәхси эшмәкәрнең яшәү урыны, исеме, фамилиясе һәм атасының исеме (булган очракта), аның шәхесен таныклый торган документ реквизитлары үзгәргәндә лицензияне яңадан рәсмиләштерү өчен түбәндәге документлар (белешмәләр) тапшырыла:<br>а) лицензияне яңадан рәсмиләштерү өчен дәүләт пошлинасы түләгәнлекне раслый торган документларның реквизитларын, лицензиат турында яңа мәгълүматларны һәм Бердәм дәүләт юридик затлар реестрына (лицензиат – юридик зат өчен), Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрына (лицензиат – шәхси эшмәкәр өчен) тиешле үзгәрешләр кертелүне раслый торган документ мәгълүматларын күрсәтеп, лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында гариза;<br>б) лицензиянең гамәлдәге чын нөсхәсе.<br>5. №99-ФЗ Федераль законның 20 статьясының 13 өлешенең 1 пунктында каралган очракта лицензия гамәлен туктату өчен күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген туктату турында гариза тапшырыла, анда күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеге фактта туктатылган көн күрсәтелә.<br>6. Лицензия дубликаты алу өчен түбәндәге документлар тапшырыла:<br>а) лицензия дубликаты бирү турында гариза, анда лицензия дубликаты бирү өчен дәүләт пошлинасы түләнгәнлекне раслый торган документ реквизитлары, яисә дәүләт пошлинасы түләгәнлекне раслый торган башка төрле мәгълүматлар күрсәтелә; | |

| | | |
|---|---|---|
| | б) бозылган лицензия кәгазе (лицензия бозылганда).<br>7. Лицензияләр реестрыннан аерым бер лицензия турында мәгълүматлар алу өчен физик заттан яки юридик заттан мондый мәгълүматларны бирү турында гариза.<br>8. Лицензия алу яки аны яңадан рәсмиләштерү (лицензия дубликаты, лицензияләр реестрыннан мәгълүматлар) өчен гариза һәм зарури документлар (документларның күчермәләре) мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә тапшырыла. | |
| 2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив-хокукый актлар нигезендә зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка төрле оешмалар карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүченең аларны тапшыру хокукы булган документларның тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен түбәндәге документлар (белешмәләр) кирәк, алар түбәндәгеләр карамагында:<br>а) Федераль казначылык – дәүләт пошлинасын түләү турында белешмәләр;<br>б) Федераль салым хезмәте – Бердәм дәүләт юридик затлар реестрында һәм Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрында булган мәгълүматлар;<br>в) Россия Федерациясенең Эчке эшләр министрлыгы – лицензия алырга теләүченең вазифаи затының икътисад өлкәсендәге җинаятьләр, уртача авырлыктагы, авыр һәм аеруча авыр җинаятьләр буенча алынмаган яки үтәлмәгән хөкем җәзасы барлыгы (булмавы) турында белешмәләр;<br>г) Россия Федерациясенең Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы – лицензия алырга теләүченең вазифаи заты турында ялгыз хуҗалыклы башкарма орган функцияләрен башкарган затлар, шулай ук лицензиатның уставы яки башка төрле документлары | № 255-ФЗ Федераль закон;<br>№ 99-ФЗ Федераль законның 14, 18 ст.;<br>№ 1110 карарның 6, 9 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | белән күпфатирлы йортларда гомуми милекне тиешенчә карап тотуны тәэмин итүгә карата таләпләр үтәлеше өчен җаваплылык йөкләнгән һәм аларга карата квалификациясеннән мәхрүм итү кебек административ җәзага тарту кулланылган затлар, лицензиясе гамәлдән чыгарылган һәм (яки) аларга карата квалификациясеннән мәхрүм итү кебек административ җәзага тарту кулланылган шәхси эшмәкәрләр реестрында мәгълүмат булу (булмау) хакында белешмәләр.<br>Мөрәҗәгать итүче, мөмкинлеге булган очракта, әлеге пунктта булган мәгълүматларны үз эченә алучы документларны тапшырырга хокуклы.<br>Мөрәҗәгать итүче югарыда күрсәтелгән мәгълүматларны үз эченә алган документларны тапшырмаса, бу мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга нигез була алмый. | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан башкарылучы һәм, норматив-хокукый актларда каралган очракларда, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен алардан килештерү таләп ителүче дәүләт хакимияте органнарының һәм аларның структур бүлекчәләренең исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Документларны кабул итүдән баш тарту каралмаган. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:<br>1) лицензия бирүдән баш тарту түбәндәге очракларда башкарыла:<br>а) мөрәҗәгать итүче тапшырган лицензия бирү турындагы гаризада һәм (яки) башка документларда (белешмәләрдә) төгәл булмаган яки ялган мәгълүмат булу;<br>б) тикшерү барышында мөрәҗәгать итүченең лицензия таләпләренә туры килмәве ачыклану;<br>в) әгәр дә лицензия алырга теләүчегә карата мондый эшчәнлек төренә карата элек бирелгән лицензияне гамәлдән чыгару карары чыгарылган булса, лицензия алырга теләүче тарафыннан лицензия бирү турында гариза һәм аңа теркәлә торган документлар тапшыру.<br>2) лицензияне яңадан рәсмиләштерүдән түбәндәге очракларда баш тартыла:<br>а) мөрәҗәгать итүче тапшырган лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында гаризада һәм (яки) башка документларда (белешмәләрдә) төгәл булмаган яки ялган мәгълүмат булу;<br>б) тикшерү барышында мөрәҗәгать итүченең лицензия таләпләренә туры килмәве ачыклану;<br>в) әгәр дә лицензия алырга теләүчегә карата мондый эшчәнлек төренә карата элек бирелгән лицензияне гамәлдән чыгару карары чыгарылган булса, лицензия алырга теләүче тарафыннан лицензияне яңадан | № 99-ФЗ Федераль законның 14 ст. |

| | | |
|---|---|---|
| | рәсмиләштерү турында гариза һәм аңа теркәлә торган документлар тапшыру.<br>3) лицензия дубликатын бирүдән баш тарту мөрәҗәгать итүче булмаган яки күрсәтелгән гамәлне кылуга вәкаләте булмаган зат гариза белән мөрәҗәгать иткәндә башкарыла;<br>4) дәүләт яки хезмәт серен саклау максатларында мондый белешмәләрдән файдалану Россия Федерациясе законнары нигезендә чикләнгән булса, бердәм лицензияләр реестрыннан мәгълүмат бирүдән баш тартыла. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасының һәм башка түләүнең тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүле нигездә күрсәтелә.<br>Дәүләт пошлинасы:<br>күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеге башкару өчен лицензия бирү – 30 000 сум;<br>күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеге башкару өчен лицензияне яңадан рәсмиләштерү – 5 000 сум;<br>күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеге башкару өчен лицензия дубликаты бирү (тапшыру) – 5 000 сум;<br>Түләү алучы:<br>Татарстан Республикасы буенча ФКИ (ТР ДТИ)<br>Түләү өчен реквизитлар:<br>Хисап счеты: № 40101810800000010001<br>Банк: БҮЛЕК – ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МБ КАЗАН Ш.<br>БИК: 049205001<br>Алучының ИНН (61) – 1653015798<br>Алучының КПП (103) – 165501001<br>КБК: 71410807400011000110 | № 99-ФЗ Федераль законның 10 ст.;<br>РФ Салым кодексының 333.33 статьясының 1 пунктындагы 134 пунктчасы |

| | | |
|---|---|---|
| | “Вәкаләтле органнарның күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген лицензияләүгә бәйле гамәлләре өчен дәүләт пошлинасы”<br>ОКТМО – Гомумроссия муниципаль берәмлекләр территорияләре нигезендә.<br>Исәп-хисап документында түләүнең билгеләнеш юлында (24) түләүнең билгеләнешен тәңгәлләштерү өчен кирәкле башка өстәмә мәгълүмат күрсәтү рөхсәт ителә<br>“Түләүче статусы” юлы (101): 08 тутыру мәҗбүри.<br>Аерым бер лицензия турындагы белешмәләр физик һәм юридик затларга бушлай лицензияләр реестрыннан өземтә, яисә кабул ителгән карар турында акт, яисә соралучы мәгълүматларның юклыгы турында белешмә рәвешендә бирелә. | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп, хезмәтләр күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамә тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтүнең | Лицензия алырга теләүче (лицензиат) тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамә тапшырылганда һәм (яки) мондый хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артып китәргә тиеш түгел. | №601 РФ Президенты Указының 1 п. |

| | | |
|---|---|---|
| нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты | Дәүләт хезмәте алучы аерым категорияләр өчен чиратлылык билгеләнмәгән. | |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамәсен теркәү вакыты | Барлык кирәкле документлары белән берлектә гариза җиткерелгән көнне. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр | Хезмәт тиешле күрсәтмәләр белән җиһазландырылган биналарда күрсәтелә.<br>Хезмәт алучыларны кабул итү мондый максатлар өчен махсус бүленгән урыннарда башкарыла, алар түбәндәгеләр белән җиһазландырылган булырга тиеш:<br>янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы;<br>документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһаз;<br>мәгълүмати стендлар. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең үтемлелек һәм сыйфат күрсәткечләре | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләр:<br>Документларны кабул итү һәм карап тикшерү вакытларын саклау;<br>Хезмәт нәтиҗәләрен алу вакытларын саклау;<br>Хезмәт күрсәтүдә катнашучы ТР ДТИ белгечләре тарафыннан кылынган Административ регламентны бозуга карата ризасызлыклар (нигезле шикаятьләр) булу.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемлелек күрсәткечләре түбәндәгеләр:<br>Бүлек биналарының җәмәгать транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;<br>Белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документларны кабул итү башкарыла торган биналарның җитәрлек күләмдә булуы; | №880 ТР МК карарының 2.4 п.<br>№601 РФ Президенты Указының 1п. |

| | | |
|---|---|---|
| | Мәгълүмати стендларда, Интернет челтәрендә, Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе рәсми сайтында хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы күләмдә мәгълүмат булу. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон рәвештә күрсәтү үзенчәлекләре | Дәүләт хезмәте электрон рәвештә күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәте күпфункцияле үзәкләрдә (алга таба – КФҮ) күрсәтелми. | |

**3. Административ процедураларны үтәү составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәүгә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә башкару үзенчәлекләре**

3.1 Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеген тасвирлау:

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү үз эченә түбәндәге административ процедураларны ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү;

2) гаризаны теркәлгән документлар җыелмасы белән берлектә кабул итү һәм теркәү яисә мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган бозуларны бетерү турында хәбәр итү;

3) ведомствоара гарызнамәләрне формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) лицензия бирү, лицензияне яңадан рәсмиләштерү, лицензия дубликаты бирү, техник хатаны төзәтү, аерым бер лицензия турында лицензияләр реестрыннан өземтә, кабул ителгән карар турында ТР ДТИ актының күчермәсе яки сорала торган мәгълүматларның булмавы турында белешмә рәвешендә мәгълүматлар бирү турында гаризаны, башка документларны карап тикшерү һәм лицензия бирү (бирүдән баш тарту), яңадан рәсмиләштерү (яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту): лицензия дубликаты бирү, техник хатаны төзәтү, аерым бер лицензия турында лицензияләр реестрыннан өземтә, кабул ителгән карар турында ТР ДТИ актының күчермәсе яки сорала торган мәгълүматларның булмавы турында белешмә рәвешендә мәгълүматлар бирү; лицензиат тарафыннан тапшырылган күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген туктатуга карата гаризага бәйле рәвештә лицензиянең гамәлен туктату турында карар кабул итү;

5) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсен тапшыру (почта аша җибәрү).

Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге Административ регламентка карата №7-12 кушымталардагы блок-схемаларда күрсәтелгән.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү.

Мөрәҗәгать итүче консультация алу өчен шәхсән үзе, телефон аша, язмача почта һәм (яки) электрон почта аша ТР ДТИ мөрәҗәгать итә.

Лицензияләүне башкаручы бүлек белгече (алга таба – бүлек белгече), мөрәҗәгать итүчене, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле булган документларның составы, рәвеше һәм эчтәлеге буенча консультацияли, мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнүче процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

Административ процедураны башкару нәтиҗәсе: консультацияләү, тапшырылган документларның составы, рәвеше һәм эчтәлеге буенча кисәтүләр, мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә күрсәтелгән ярдәм.

3.3. Дәүләт хезмәте алу өчен лицензия алырга теләүче, лицензиат ТР Административ регламентның 2.5 пунктында каралган гаризаны һәм документларны (белешмәләрне) ДТИ турыдан-туры тапшыра яки почта аша, кулга тапшыру белдерүнамәсе белән, заказлы хат итеп яки Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталыннан файдаланып җибәрә.

3.3.1. Бүлек белгече түбәндәгеләрне башкара:

гаризаны һәм башка документларны исемлек буенча кабул итә;

гаризаны Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнарының бердәм ведомствоара электрон документ әйләнеше системасында (алга таба – Электрон Хөкүмәт) терки;

лицензия алырга теләүчегә, лицензиатка, кабул итү көне турында күрсәтеп, күрсәтелгән гаризаларның һәм документларның исемлеге күчермәсен тапшыру яки почта аша, кулга тапшыру турында белдерүнамә белән, заказлы хат итеп җибәрү.

Әлеге пунктта билгеләнүче процедура тиешле документлары белән берлектә гариза ирешкән көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлүче документлары белән берлектә теркәлгән гариза.

3.3.2. Бүлек белгече, Административ регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән таләпләрне бозып рәсмиләштерелгән гариза алынган очракта, аларны кабул иткәннән соң 3 эш көне дәвамында лицензия алырга теләүчегә ачыкланган бозуларны утыз көн эчендә бетерергә кирәклеге турында белдерүнамә (алга таба – бозуларны бетерү турында белдерүнамә) тапшыра яки мондый белдерүнамәне почта аша, кулга тапшыру белдерүнамәсе белән, заказлы хат итеп җибәрә.

Бозуларны бетерү өчен билгеләнгән утыз көнлек вакыт лицензия алырга теләүченең, лицензиатның мондый белдерүнамәне алган көне документ белән расланган көннән башлап хисаплана.

Лицензия алырга теләүче, лицензиат, утыз көн эчендә Административ регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән гаризаны һәм документларны (белешмәләрне) тулы күләмдә тапшырмаган очракта, 3 эш көне дәвамында лицензия алырга теләүчегә, лицензиатка, кайтарып бирүнең сәбәпләрен дәлилле нигезләп, гаризаны һәм аңа теркәлә торган документларны кире кайтару турында белдерүнамә тапшырыла яки почта аша, кулга тапшыру белдерүнамәсе белән, заказлы хат итеп җибәрә.

Административ регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән таләпләр нигезендә рәсмиләштерелгән гариза һәм документлар (белешмәләр) тулы күләмдә тапшырылган очракта, яисә бозуларны бетерү турындагы белдерүнамәдә күрсәтелгән бозуларны бетергәндә, бүлек белгече гаризаны һәм документларны кабул иткәннән соң 3 эш көне дәвамында лицензия алырга теләүчегә, лицензиатка аларның ТР ДТИ тарафыннан карап тикшерүгә кабул ителүе хакында, шул исәптән мәгълүмати-коммуникация технологияләре ярдәмендә хәбәр итә, ә лицензия бирү турында гариза килгән очракта, лицензия алырга теләүчегә карата планнан тыш урынга чыгып тикшерү үткәрү хакында боерык (әмернамә) проекты әзерли

Процедураның нәтиҗәсе: бозуларны бетерү турында белдерүнамә, гаризаны һәм аңа теркәлүче документларны кире кайтару турында белдерүнамә, лицензия алырга теләүчегә, лицензиатка гаризаны һәм аңа теркәлүче документларны кабул итү турында хәбәр итү, планнан тыш урынга чыгып тикшерү үткәрү турында боерык (әмернамә) проекты.

3.3.3. ТР ДТИ тарафыннан гариза карап тикшерүгә алынган көннән соң килүче көннән соңга калмыйча, бүлек белгече ведомствоара гарызнамәләр

формалаштыра һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында ведомствоара хезмәттәшлек итү түбәндәгеләр белән гамәлгә ашырыла:

1) Россия Казначылыгы – дәүләт пошлинасы турында белешмәләр алу өчен;

2) Россиянең ФСХ – Бердәм дәүләт юридик затлар реестрында һәм Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрында булган мәгълүматларны алу өчен;

3) Россия ЭЭМ – икътисад өлкәсендәге җинаятьләр, уртача авырлыктагы, авыр һәм аеруча авыр җинаятьләр буенча алынмаган яки үтәлмәгән хөкем җәзасы барлыгы (булмавы) турында белешмәләр алу өчен.

4) Россия Федерациясенең Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы – лицензия алырга теләүченең вазифаи заты турында ялгыз хуҗалыклы башкарма орган функцияләрен башкарган затлар, шулай ук лицензиатның уставы яки башка төрле документлары белән күпфатирлы йортларда гомуми милекне тиешенчә карап тотуны тәэмин итүгә карата таләпләр үтәлеше өчен җаваплылык йөкләнгән һәм аларга карата квалификациясеннән мәхрүм итү кебек административ җәзага тарту кулланылган затлар, лицензиясе гамәлдән чыгарылган һәм (яки) аларга карата квалификациясеннән мәхрүм итү кебек административ җәзага тарту кулланылган шәхси эшмәкәрләр реестрында мәгълүмат булу (булмау) хакында белешмәләр алу өчен.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәтләрен күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрелүче гарызнамәләр.

3.3.4. Лицензия алырга теләүченең лицензия таләпләренә туры килүенә карата урынга чыгып планнан тыш тикшерү үткәрү турында ТР ДТИ боерыгы (әмернамәсе) ТР ДТИ башлыгы (башлык урынбасары) тарафыннан имзалана.

Бүлек белгече, Административ регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгәнчә рәсмиләштерелгән гариза һәм документлар ТР ДТИ ирешкәннән соң 10 эш көне дәвамында, алардагы мәгълүматларның тулылыгын һәм төгәллеген тикшерә, түбәндәгеләрне бәяләү максатында:

а) мәгълүматның Административ регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән аерым документлар белән килештерелгән булуын;

б) Административ регламентның 3.3.3 пункты нигезендә ТР ДТИ тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү юлы белән алынган лицензия алырга теләүче турындагы белешмәләрнең ярашлы булуын.

Тапшырылган белешмәләрнең тулылыгын һәм төгәллеген тикшерү нәтиҗәләре буенча акт төзелә.

Лицензия алырга теләүчене планнан тыш урынга чыгып тикшерү, билгеләнгән тәртиптә прокуратура органнары белән килештерелмичә, лицензияләүче органга тиешле тәртиптә рәсмиләштерелгән гариза һәм документлар кергәннән соң 20 көннән узмаган чорда үткәрелә.

Лицензия алырга теләүченең лицензия таләпләренә туры килү-килмәвен урынга чыгып планнан тыш тикшергәндә түбәндәгеләр тикшерелергә тиеш:

а) лицензия алырга теләүченең Россия Федерациясе территориясендә юридик зат яки шәхси эшмәкәр буларак теркәлгән булуы;

б) лицензия алырга теләүченең җитәкчесендә яки төзелгән шартнамә нигезендә юридик зат белән агымдагы идарәлек итүгә вәкаләт бирелгән оешма вәкилендә гамәлдәге квалификация аттестаты булу;

в) лицензия алырга теләүченең вазифаи затының икътисад өлкәсендәге җинаятьләр, уртача авырлыктагы, авыр һәм аеруча авыр җинаятьләр буенча алынмаган яки үтәлмәгән хөкем карары булмавы;

г) лицензиясе гамәлдән чыгарылган лицензиатның ялгыз хуҗалыклы башкарма орган функцияләрен башкарган затлар, шулай ук лицензиатның уставы яки башка төрле документлары белән күпфатирлы йортларда гомуми милекне тиешенчә карап тотуны тәэмин итүгә карата таләпләр үтәлеше өчен җаваплылык йөкләнгән һәм аларга карата квалификациясеннән мәхрүм итү кебек административ җәзага тарту кулланылган затлар, лицензиясе гамәлдән чыгарылган һәм (яки) аларга карата квалификациясеннән мәхрүм итү кебек административ җәзага тарту кулланылган шәхси эшмәкәрләр реестрында лицензия алырга теләүченең вазифаи заты турында мәгълүмат булмау;

д) җыелма федераль лицензияләр реестрында лицензия алырга теләүчегә элегрәк бирелгән күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлегенә карата лицензиянең гамәлдән чыгарылуы турында мәгълүмат булмау;

е) лицензия алырга теләүченең мәгълүмат ачуга карата Россия Федерациясе Торак кодексының 161 статьясының 10 өлешендә билгеләнгән таләпләрне үтәве.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырылган белешмәләрнең тулылыгын һәм дөреслеген тикшерү акты, планнан тыш урынга чыгып үткәрелгән тикшерү акты.

3.3.5. Лицензия алырга теләүчене планнан тыш урынга чыгып тикшерү тәмамланганнан соң 2 эш көне дәвамында бүлек белгече, тапшырылган мәгълүматларның тулылыгын һәм дөреслеген тикшерү һәм урынга чыгып үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасының лицензия комиссиясе өчен материаллар әзерли, түбәндәге тәкъдимнәр белән:

а) лицензия бирү турында – лицензияне бирүдән баш тарту өчен Административ регламентның 2.9 пунктында билгеләнгән нигезләр булмаган очракта;

б) лицензияне бирүдән баш тарту турында – лицензияне бирүдән баш тарту өчен Административ регламентның 2.9 пунктында билгеләнгән нигезләр булганда.

Материаллар һәм ТР ДТИ тәкъдимнәре, лицензия бирү өчен гариза һәм аңа теркәлә торган документлар, лицензия алырга теләүчедән кергән тиешле тәртиптә рәсмиләштерелгән гариза һәм башка документлар теркәлгән көннән алып 30 эш көненнән дә соңга калмыйча, лицензия бирү турында яисә лицензия бирүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен Татарстан Республикасы лицензия комиссиясенә җибәрелә.

Татарстан Республикасының лицензия комиссиясе ТР ДТИ тарафыннан җибәрелгән материалларны карап тикшерә һәм, күрсәтелгән материаллар кергән датадан соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, аның эшчәнлеге турындагы Нигезләмә нигезендә карар чыгара. Татарстан Республикасының лицензия комиссиясенең карары, кабул ителгәннән соң 3 эш көне дәвамында, ТР ДТИ җибәрелә.

Процедураның нәтиҗәсе: Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе карары.

3.3.6. ТР ДТИнең лицензия бирү турындагы боерыгы лицензия комиссиясе карары алынганнан соң 2 эш көне дәвамында чыгарыла.

ТР ДТИнең лицензия бирү турындагы боерыгы һәм лицензия бер үк вакытта ТР ДТИ башлыгы тарафыннан имзалана һәм лицензияләр реестрында теркәлә.

ТР ДТИнең лицензия бирү турындагы боерыгы һәм лицензия түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

а) лицензияләүче органның исеме – ТР ДТИ;

б) юридик затның тулы һәм (булган очракта) кыскартылган исеме, шул исәптән фирма аталышы, оешу-хокукый рәвеше, аның урнашу адресы, лицензияләнә торган эшчәнлек төрләре башкарыла торган урыннарның адреслары, юридик зат булдыру турындагы язуның дәүләт теркәвенә алыну номеры;

в) салым түләүченең тәңгәллек номеры;

г) лицензияләнүче эшчәнлек төре – күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеге;

д) лицензия номеры һәм теркәлү номеры;

е) боерык номеры һәм датасы.

Лицензия Административ регламентка карата №6 кушымта рәвешендәге, катгый хисаплылыкка ия булган һәм ялганлап ясаудан якланган полиграфия продукциясе булган ТР ДТИ кәгазендә рәсмиләштерелә.

Лицензияне имзалагач һәм теркәгәннән соң 3 эш көне дәвамында бүлек белгече лицензияне мөрәҗәгать итүчегә (Россия Федерациясе законнарындагы таләпләр нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә вәкаләтле затка) имзалатып тапшыра яки, кулга тапшыру турындагы белдерүнамә белән, почта аша заказлы хат итеп җибәрә, шулай ук бу хакта лицензиатка элемтә чаралары аша һәм тиешле мәгълүматны ТР ДТИ рәсми сайтында https://gji.tatar.ru урнаштыру юлы белән хәбәр итә.

Татарстан Республикасының лицензия комиссиясенә лицензия бирүдән баш тарту турында тәкъдим әзерләгән очракта, бүлек белгеченә, мондый баш тартуга нигез булып торган норматив-хокукый актларның һәм башка документларның аерым бер нигезләмәләренә сылтама ясап, баш тартуның дәлилле нигезләрен, яисә, әгәр дә баш тартуның сәбәбе булып тикшерү барышында лицензия алырга теләүченең лицензия таләпләренә туры килмәве ачыклану торса, лицензия алырга теләүчене тикшерү акты реквизитларын күрсәтергә кирәк. Материалларны карап тикшерү һәм лицензия бирүдән баш тарту турында карар кабул итү Татарстан Республикасының лицензия комиссиясе тарафыннан күрсәтелгән материаллар кергән датадан башлап 10 эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

ТР ДТИнең лицензия бирүдән баш тарту турындагы боерыгы Татарстан Республикасының лицензия комиссиясе карары алынганнан соң 2 эш көне дәвамында чыгарыла.

ТР ДТИнең лицензия бирүдән баш тарту турындагы боерыгы имзаланганнан соң 3 эш көне дәвамында бүлек белгече лицензия алырга теләүчегә лицензия бирүдән баш тарту турында белдерүнамә тапшыра яки, кулга тапшыру турындагы белдерүнамә белән, почта аша заказлы хат итеп җибәрә. Лицензия бирүдән баш тарту турында белдерүнамәдә, мондый баш тартуга нигез булган норматив-хокукый актларның һәм башка документларның аерым бер нигезләмәләренә сылтама ясап, баш тартуның дәлилле нигезләре күрсәтелә. Әгәр баш тартуның сәбәбе булып тикшерү барышында лицензия алырга теләүченең лицензия таләпләренә туры килмәве ачыклану торса, лицензия алырга теләүчене тикшерү акты реквизитлары күрсәтелә. Лицензия бирүдән баш тарту турында белдерүнамә лицензия алырга теләүчегә шулай ук мәгълүмати-коммуникация технологияләре ярдәмендә дә җибәрелергә мөмкин.

Лицензияләү процедурасы тәмамланып, лицензия тапшырылганнан соң (алынганнан соң) 5 (биш) эш көне дәвамында бүлек белгече түбәндәге документлардан торучы лицензия эше формалаштыра:

а) лицензия алырга теләүченең лицензия бирү турындагы гаризасы, лицензиат гаризасы һәм тиешле гаризага теркәлә торган документлар;

б) ТР ДТИнең лицензия бирү турында, лицензия бирүдән баш тарту турында, лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында, лицензияне яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту турында, лицензия гамәлен туктату, техник хата төзәтү, дубликат бирү турындагы боерыклары;

в) имзаланган һәм теркәлгән лицензиянең күчермәсе;

г) ТР ДТИнең лицензия алырга теләүчегә, лицензиатка карата тикшерү билгеләү турында боерыклары, тикшерү актларының, ачыкланган лицензия таләпләрен бозуларны бетерү турында күрсәтмәләрнең, административ хокук бозулар турындагы беркетмәләрнең, административ җәзалар билгеләү турындагы карарларның һәм башка, лицензия контролен башкаруга бәйле документларның күчермәләре;

д) лицензияне гамәлдән чыгару турында суд карарларыннан өземтәләр;

е) лицензияләүгә бәйле белдерүнамәләрнең һәм башка документларның күчермәләре.

Лицензия эше, мөрәҗәгать итүчегә лицензия бирелү-бирелмәүгә карамастан, ТР ДТИдә вакыты чикләнмәгән күләмдә мәгълүматның кагылгысызлыгын тәэмин итү кагыйдәләрен үтәп саклана.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензия бирү турында боерык, лицензияләр реестрында теркәү, лицензия, лицензия бирүдән баш тарту турында боерык, баш тарту турында белдерүнамә, лицензия эше.

3.3.7. Лицензиядә техник хата киткән очракта лицензиат ТР ДТИ түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза;

техник хата киткән лицензиянең чын нөсхәсе;

техник хата барлыгын таныклаучы һәм юридик көчкә ия булган документлар.

Техник хата дигәндә ТР ДТИ тарафыннан җибәрелгән һәм лицензиягә кертелгән белешмәләрнең, алар нигезендә белешмәләр кертелүче документлардагы белешмәләрнең төгәлсезлегенә китергән хата (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата) аңлашыла.

Бүлек белгече документларны карап тикшерә һәм, нигезләр булган очракта, лицензиягә төзәтмәләр кертү максатларында техник хатаны төзәтү турында боерык проекты әзерли.

ТР ДТИнең техник хатаны төзәтү турындагы боерыгы һәм лицензия бер үк вакытта ТР ДТИ башлыгы тарафыннан имзалана һәм лицензияләр реестрында теркәлә.

Имзаланган һәм теркәлгән лицензия лицензиатка (Россия Федерациясе законнарындагы таләпләр нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә вәкаләтле затка) имзалатып тапшырыла яки, кулга тапшыру турындагы белдерүнамә белән, почта аша заказлы хат итеп җибәрелә.

Техник хата җибәрелгән лицензия акт нигезендә юк ителә.

Әлеге пунктта билгеләнүче процедура лицензиядә киткән язудагы хатаны, басмадагы хатаны, грамматик яки арифметик хатаны төзәтү турында гариза һәм башка документлар кергәннән соң 10 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында боерык, лицензияләр реестрында теркәү, лицензия.

3.4. Лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында гариза юридик затны үзгәртеп төзү рәвешендә үзгәртеп корганда, аның аталышы, урнашу урынының адресы, юридик зат тарафыннан лицензияләнүче эшчәнлек төрләре башкарылучы урыннарның адреслары, лицензияләнүче эшчәнлек төрен хасил

итүче башкарылучы эшләрнең, күрсәтелүче хезмәтләрнең исемлеге үзгәргән очракта тапшырыла.

Юридик затны үзгәртеп төзү рәвешендә үзгәртеп корганда лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында гариза һәм башка документлар (белешмәләр) тиешле үзгәрешләр Бердәм дәүләт юридик затлар реестрына кертелгәннән соң 15 эш көненнән дә соңга калмыйча ТР ДТИ тапшырыла.

Юридик затларны берләштерү рәвешендә үзгәртеп корганда лицензияне яңадан рәсмиләштерү бары тик берләштерүдә катнашучы һәр юридик затның дәүләт теркәвенә алыну көненә үзгәртеп корылган юридик затларның хокукый варисында күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеге башкару өчен лицензиясе булган очракта гына рөхсәт ителә.

3.4.1. Лицензияләүче органга тиешле тәртиптә рәсмиләштерелгән лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында гариза кергәннән соң 5 эш көненнән дә соңга калмыйча бүлек белгече, лицензия эшендәге лицензиат турында булган белешмәләрне исәпкә алып, тапшырылган белешмәләрнең тулылыгын һәм дөреслеген тикшерә, түбәндәгеләрне ачыклау максатында:

1) лицензияне яңадан рәсмиләштерү өчен нигезләр булуны;

2) гаризада тапшырылган белешмәләрнең тулылыгын һәм дөреслеген тикшерү һәм аларны Административ регламентның 3.3.3 пункты нигезендә ТР ДТИ тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү юлы белән алына торган белешмәләр белән чагыштыру өчен.

Тапшырылган белешмәләрнең тулылыгын һәм дөреслеген тикшерү нәтиҗәләре буенча акт төзелә.

Лицензиат тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең тулылыгын һәм дөреслеген тикшерү тәмамланганнан соң 2 эш көне дәвамында бүлек белгече лицензияне яңадан рәсмиләштерү (лицензияне яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту) турында боерык проекты әзерли.

Лицензияне яңадан рәсмиләштерү өчен боерык проекты, гариза һәм документлар ТР ДТИ башлыгы тарафыннан 2 эш көне дәвамында, ләкин лицензиаттан кергән тиешле тәртиптә лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында гариза теркәлгән датадан соң 9 эш көненнән дә соңга калмыйча, лицензияне яңадан рәсмиләштерү яки лицензияне яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту турында карар кабул итү максаты белән карап тикшерелә.

ТР ДТИнең лицензияне яңадан рәсмиләштерү турындагы боерыгы һәм лицензия бер үк вакытта ТР ДТИ башлыгы тарафыннан имзалана һәм лицензияләр реестрында теркәлә.

Аңа алмашка яңадан рәсмиләштерелгән лицензия бирелгән лицензия акт нигезендә юк ителә.

ТР ДТИнең лицензияне яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту турында боерыгының проекты әзерләнгән очракта, бүлек белгеченә, мондый баш тартуга нигез булган норматив-хокукый актларның һәм башка документларның аерым бер нигезләмәләренә сылтама ясап, баш тартуның дәлилле нигезләрен күрсәтергә кирәк.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырылган белешмәләрнең тулылыгын һәм дөреслеген тикшерү акты, лицензияне яңадан теркәү турында боерык, лицензияләр реестрында теркәү, лицензия, лицензияне яңадан теркәүдән баш тарту турында боерык, баш тарту турында белдерүнамә.

3.5. Бүлек белгече, лицензия дубликаты бирү турында тиешле тәртиптә рәсмиләштерелгән гариза ТР ДТИ килеп ирешкән көннән алып 3 эш көне дәвамында, лицензия эшендә лицензиат турындагы мәгълүматларны исәпкә алып, җиткерелгән мәгълүматларның тулылыгын һәм дөреслеген тикшерә, түбәндәгеләрне ачыклау максатында:

лицензия дубликаты бирү өчен нигезләр булуны;

гаризада тапшырылган белешмәләрнең тулылыгын һәм дөреслеген тикшерү һәм аларны Административ регламентның 3.3.3 пункты нигезендә ТР ДТИ тарафыннан Россия Казначылыгы белән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү юлы белән алынган мәгълүматлар (лицензия дубликаты алу өчен түләнгән дәүләт пошлинасы) белән чагыштыру өчен.

3.5.1. Лицензия дубликаты бирү турында Административ регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән таләпләр нигезендә тиешле тәртиптә рәсмиләштерелгән гариза һәм документлар (белешмәләр) кабул ителгән көннән алып 3 эш көне дәвамында һәм тапшырылган гаризаның һәм документларның тулылыгын һәм дөреслеген тикшерү нәтиҗәләре буенча акт төзелә.

Боерык проекты, лицензия дубликаты бирү өчен гариза һәм документлар ТР ДТИ башлыгы тарафыннан, лицензиаттан кергән тиешле тәртиптә лицензия дубликаты бирү турында гариза теркәлгән датадан соң 3 эш көне дәвамында, лицензия дубликаты бирү турында карар кабул итү максаты белән карап тикшерелә.

ТР ДТИнең лицензия дубликаты бирү турындагы боерыгы һәм лицензия дубликаты лицензия кәгазендә “дубликат” һәм “лицензиянең чын нөсхәсе гамәлдән чыккан дип таныла” дигән язу теркәп, бер үк вакытта ТР ДТИ башлыгы тарафыннан имзалана һәм лицензияләр реестрында теркәлә.

Бүлек белгече лицензия дубликатын лицензиатка тапшыра яки, кулга тапшыру турындагы белдерүнамә белән, почта аша заказлы хат итеп җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырылган белешмәләрнең тулылыгын һәм дөреслеген тикшерү акты, лицензия дубликаты бирү турында боерык, лицензия дубликаты, лицензияләр реестрында теркәү.

3.6. Лицензияләр реестрында булган, аерым бер лицензияләр турында язмача бирелгән өземтә, Татарстан Республикасының лицензия комиссиясе кабул иткән карарлар турында актлар, соралучы мәгълүматларның булмавы турындагы белешмәләр рәвешендәге мәгълүмат физик һәм юридик затларга аларның гаризасы нигезендә бушлай бирелә.

Бүлек белгече, лицензияләр реестрында булган мәгълүматны бирү турындагы гариза ТР ДТИ ирешкәннән соң, лицензияләр реестрыннан өземтә, Татарстан Республикасының лицензия комиссиясе кабул иткән карарлар турында акт күчермәсе яисә соралучы мәгълүматларның булмавы турында белешмә әзерли.

Лицензияләр реестрыннан мәгълүмат бирү вакыты тиешле гариза кергәннән соң 5 эш көненнән дә артып китә алмый.

